ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.07.2024 с.Старое Дрожжаное № 294

Шәһәр төзелеше һәм архитектура өлкәсендә аерым административ регламентларның үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Үз көчен югалткан дип таныпга:

– Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында» 28.06.2019 № 274 карары белән расланган капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

– «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 29 июнендәге 252 номерлы карары белән расланган рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

– «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы

башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 14 июлендәге 283 номерлы карары белән расланган җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

– «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 21 июлендәге 294 номерлы карары белән расланган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

– «Шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлегенең аерым административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 21 сентябрендәге 408 номерлы карары белән расланган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне, документларны, материалларны күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Баһаутдиновка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Р.И. Мөхәммәтҗанов